

Узган шимбәдә Ельник районы Акчеево авыл жирлеге халкы Дан орденынын тулы кавалеры Мещеров Зариф Ибраһим улынын 100 яшьлеген билгеләп үттеләр.
Ана йоз яшь тулыр иде, әмма ул кырык биш яшендә вафат булган. Боек Ватан сугышында сапер буларак, ул гел тормыш һәм үлем арасында булган. Зариф Ибраһим улынын гаять кыюлыгы иптәшләренен гомерен саклап калуда, илне азат итүдә һәм фашист илбасарларын тар-мар итүдә. Анын унышлы хәрби операцияләр ясавы батырлыгы турында сойли. Мордовия татарлары һәм анын якташлары Зариф Ибраһим улы Мещеров белән горурлана. Сугыш герое турында хәтер мәнгегә йорәкләрдә булыр. Анын исемен лаеклы рәвештә Акчеево мәктәбе йортә һәм узган чара шуна ачык мисал. Әтисен искә алу кичәсендә Зариф Ибраһимовичнын улы Ариф Зариф улы, шулай ук анын оныгы, онык чыгы, туганнан туганы белән бергә авыл халкы жыелган. Акчеево авыл жирлеге башлыгы Петр Михайлович Ямщиков барысын да жылы сәламләгән һәм Зариф Ибраһим улы кебек кешеләр жирнен горурлыгы дип сойләгән. «Ватанга тугрылыклы һәм гадел хезмәт иткән чын патриот ул. Һәрвакыт яшь буын очен патриотизм үрнәге булачак», - дип тә остәгән.
Концерт программасында укытучылар коллективы, мәктәп укучылары белән бергә, чыгыш ясаганнар. Сугыш героенын сугышчан юлы һәм сугыштан сонгы тормышы турында тантананы алып баручы Румия Кәмил кызы Шехмаметьева сойләгән.
Ариф Зариф улы Мещеров якташларына мөрәжәгать итеп: «Әти турында истәлекләрне шулай саклаганыгыз очен рәхмәт сезгә, кадерле якташлар! Бу сугышчан батырлык кылган кешеләргә генә кирәк түгел; без алар турында дога кыла алабыз, барыннан да элек, бу безнен балаларга кирәк. Чонки хәтер - киләчәктә хаталардан саклану дигән сүз. Россия тарихында безнен иреккә кул сузучылар күп иде, ләкин А.Невский: «Туп белән кем килер, туптан һәлак та булыр», - диде. Бу канкойгыч сугышта да шулай булды. Хәтеребез исән чакта шулай булачак». Ариф Зариф улы «Офицерлар» кинофильмыннан юллар укыды: «Аларга егерме биш яшь булмаса да, авыр юлны үтәргә туры килде... »
Боек Ватан сугышы башланганда Зариф Ибраһим улына да егерме биш яшь була. Ул кон саен зур батырлыклар күрсәткән. Анын батырлыклары һәм иптәшләренен батырлыклары Ватаныбызны Боек Жинүгә китерде, ә Зариф Ибраһим улы Мещеровнын исеме Россия тарихына алтын хәрефләр белән язылады.
Чара ахырында Акчеево авылындагы Ватаныбызны азат итүче геройлар һәйкәленә чәчәкләр салынган.

Наилә НАСЫРОВА